**Хәбип НАҖАР**
**(Габдельнур Сәлимов)**

# ӘҮЛИЯЛӘР МИЗГЕЛЕ

Бакый Урманчедан соң ана телен да шигырьләр да язарлык куәсе булган рәссам белен тәүге очрашуыбыз түгел микән бу?.. Нәфис сәнгать тарихында Мәшһүр кәсепкяр-профессионалларның кызыксындырырдай язма мирас калдыручылары, каләм әһелләренә тиңләшерлек маһирлары атлаган саен очрап та тормый бит әле, – «Әүлияләр мизгеле»н уку барышында менә шул сирәк үзлекне күңелдә тоткан көйгә иҗатчының «халәте рухия»се югарылыгына таба хет бер генә мәртәба булса да йөрәксенеп куйсак иде. Шомалыктан бигрәк югарылык белән алдыра торган, «и югарылык белен типкән вә селкенген күңел!» шикелле юлларны хәерде яңартып-яңартып та җибәрә торган иҗат бугай бу... милли җанлы иҗат! Гомерендә беренче мәртәбә күңеленә шигырь килгән рәссамның шомалык турысында тәҗрибәсе дә, басылып кына эшләп утырырлыгы да булмагандыр инде: 1995 елның азакларыннан 1996 елның башларына кадерге бер тар гына вакыт аралыгында сиксәнлеп шигырь яралган да куйган. Араларында йөзе килмәген чиерекләре дә, узенә бертөрле рух тереклеген... әүлияләр-ферештәләр тереклеген бөтен тулылыгында, бөтен байлыгында, нурлы-йөгрек хәрәкәттә күрсәтүгә ирешкән «Мизгел» кебек тәэсирләндерерлекләре дә бар. Әүлиялер мизгеле! «Әүлия» сүзенең «изге кеше» кебек күнегелгән гадәти мәгънәсенә яңачарак бер төсмер салынып, шигырьдә ул ачылып-балкып та киткач, андый мизгелнең «бер көн Раббың каршында мең ел кебектер» дигән аятькә бик тә рас килүен аңышасың. Шундый мизгел бу, анда – мәңгелек, анда – югарылык, анда – савап. Инде килеп бу тупламның дәһшәтле көннердә, тулы бер миллетне юк итү сәясәте алып барылган, Ичкерия өстенә үлем яудырылган вакытларда иҗат ителүен, үзебезне монда сикерткеч-кикерткеч көйләр, тозсыз мәзәкләр белән изеп, көчсезләндереп, сыеклатып ятканнарын да исәпкәалсан... Ул каһәрле көннәрдә иҗатчы әүвәлге һәм соңгы сыенычына юл ала... Ходайга сыгына. Ходай хозурлыгына мохтаҗлыгын аклый... Күңелнең Ходайны юксыну әхвәлен, югарылыкны тансыклау халәтен соңыннан да саклый-кадерли алгандырмы иҗатчы, шигырь агымыннан кабат җилкенгендерме, билгесез, әмма ни булса да шушы бәләкәй генә туплам барыбер әдәби хәрәкәткә катышырга, хәрәкәттәгеләрне бер уйландырырга тиештер бит? Уйланмыйча да булмый, борын төбендә – яңа дәвер... постиндустриаль цивилизация. Бетте ул баш өстендә камчы уйнатулар, акыру-бакырулар, бетте ул ут-төтен бөркеп торган шау-шулы завод-кярханәләр комплексын төп икътисади фактор дип санаулар. Татар бу яңа дәверге нинди әзерлектә керә? Рухи халате әзерме моңа? Иң беренче чиратта күңел дөньясына юнәлтелгән дәвер ләбаса бу... Һөҗүм алып барыла, аяусыз һөҗүм күңел дөньясына. Компьютер уеннары, клиплар, масскультура, дизайн дәрәҗәсенә төшкән сурәтчелек, тагын әллә ниләр бөтенесе бер максатка хезмәт итә: адем баласын мәҗүсилектә тоту. Сәерме? Постиндустриаль цивилизация – һәм мәҗүсилек. Белдекле галим-големә бу күренешне «виртуаль чынбарлык», «виртуаль режимда яшәү» дип, уратып-уратып кына язгалый да инде... Сүз монда андагы (сознание)

хәрәкәт турында бара... Чытырманлыкларга кереп китүдән саклана төшебрәк әйткәндә, болаерак шикелле: аңдагы җемелдеклер, өерелешләр, клип-реклама уйнаклавыдай буталышлар акылны (разум) томалый; еланнар белен буылып алынган Лаокоон чарасызлыгына төшеп, көн итмешендә сулыштан да газизрәк булган асыл кәлимәдән, күңелне ныгыта вә пакьлый торган «лә иләһә илләл-лаһ» кәлимәсеннән - теүхидтән биздерелү адәм углы, Аллаһы Тәгалә хозурлыгы белен күңел арасында пәрдә тартыла!

Сүз сөреше сәнгать турында иде бит моның, ник кырыйга чалулап алып кереп китте соң әле бу, дигән уй киләдер. Юк, фикер җебе чуалмаган, фикер җебе гел бер якка савыла... Яңа дәвергә әзерлегебезне, рухи халәтебезнең яңа цивилизациягә ярашлылык җәһәтен рәссамнарыбыздан да мәгънәлерәк гәүдәләндерүчеләр юктыр, ахрысы – нәкъ менә алар «дөньякүләм кимәлдә» эш итә... Әмма кемнәр мәслегендәге кимәлдә?! Кемнер югарылыгында? «Югарылык» дигәнең дә бит әле ул ике төрле: бар берсе – илаһиятке күңелне алгысыткан югарылык, бар тагын икенчесе... Хәлиткеч сорау: милли сәнгать кайсы якны якын итә? Сәнгатькярнең күңеле кайсы югарылыкка тартыла, кайсы яктагы «затлар»дан рухлана?! Кисәтүле якгырый башламыймы Бакый Урманченың «белгәнгә – ялгыш, белмәгәнгә – нәгышь» дигән һуш китмәле мәкале? «Камиллекнең чиге юк, зеүкый ләззәткә ирешкәнче чарлый әсәрен талант иясе» дигәнрәк фикердән тыш тагын яңа... хәтер мәгънә ишетелеп китмиме?! Нинди халәттә эшләнгән эш кабул була... ялгыш булмый?!

Кыскасы, шул: руханилар иҗатына мохтаҗбыз! Бу сүзләр гадәттәгечә көлкегә алыныр, билгеле, әмма ничек кенә гаҗәп тоелмасын, яңа дәвердә, могҗизави яңа цивилизациядә күңелләрне руханилык кына алып калачак, ныгытачак, һәм киләчәк тарафыннан бәһаләнәсе асыл сыйфат та – шул гына, Коръән-Кәрим белән вәгазьләнеп яшәү вә иҗат итү генә! Вәссәлам.

...Күңелләр – Лаокоон!

Бу хакта байтак баш ватканнардыр, мөназәрәләр дә кылышмый калмаганнардыр Башкортостан рәссамнары... Иҗатчыбызның Туймазыдан икәнлеге әйтелми тора икән бит... Аның мәгълүм «Чыңгызхан» төркеме рәссамнары белән дустанә мөнәсәбәте, шул төркемнең узаманы вә фикерчесе, инде мәрхүм Наил Латфуллин белән үз заманында рухи туганлыгы да нәкъ менә әлеге үзәккә үткән эзләнүләрдән киләдер, бәлкем?.. Кайберәүләр хәтерлидер дә әле Наил Латфуллинның «Философ» дигән әсәрен, «Казан утлары»нда нәшер ителгән иде ул: Күккә «кәҗә тоягы» күрсәтеп ятучы ак жиңле безнең кул... татар кулы! Гасыр чире! Алласызлык. Бу чиргә дәрман бармы? – Үзебездәме ул дәрман – культурабызда яисә тарихыбыздамы, мәҗүсилек-тәнречелек дәверләрендәме, әллә инде күңелебездәме, яки булмаса галәмдәме? Кайда мәсләк, кайда көч вә куәт, кайда тәвәккәллеккә китерерлек кодрәт?

Күңел – Лаокоон!

...Лаокоонлык татарның «философ» булып китүеннен башлангандыр. «Җәдитчелек» дип йөртелгән ул хәрәкәтнең чын йөзен Сәйфи Кудаш Хәсән Туфанга язган бер хатында шартлатып ачкан да салган: «Ул бөек остазыбыз

Зыя ага (Зыя Камали – «Талия» мәдрәсәсенең мөдире), бәлки үзе дә сизмәгән хәлдә, «материализма юнәлдерде безне». (Ассызык – безнеке). Дәһрилек. ягъни мәсәлән. Шәрехләүләр артык, диләр инде мондый очракта. Олуг исемнәргә тел тидерүдә гаепләүчелер булса, жавап: Сейфи Кудашның кадерсезлеккә төшкәндәй аулакта нәүмизләнеп яткан шигырьләр тупламын хәл кадеренчә зурлап, «Аргамак» журналы быелның җиденче санында дөньяга чыгарды. Җәдитчелеккә ябышып катканнар күрделәр микән, кадерли беләләр микән, карап карыйк...

Бу булды «философлыкның» XX гасыр башындагы чын йөзе. Инде күчик XIX гасырга. Татар даһиена бирелген бер сыйфатлама: «...ул акрынлап мөселман догматизмындагы схоластик богауларны җимереп, фәлсәфәдә яңа үрләр яулый, аның пантеистик карашлары формалаша. Аның пантеизмында... алланы табигатьтә эретү тенденцияләре ачык сизелә».

Бу гыйльми өзектән соң Хәмит Латыйповның «Тавыш» диген рәсеменә күчү мәслихәттер. «Богауларны җимерү», «алланы табигатьтә эретү» кебек сүзләрнең мәгънәсен ачарга ярдәм итмәсме... Учын колагына куеп, ниндидер өннәргә күңел салучы карт; намазлыгына кырын яткан, төнге күккә йотылган... Түбәтәе, буй-буй ыштаны, башмагы, намазлыгы айлы күктән аерып алгысыз... бер халәттә. Суфыйларны хәтерләте карт. Борынгы шигырь юлларын искә төшереп китү урынлы булыр бу очракта:

Арслан менеп йиләрләр,
Еланны камчы кыларлар
Башын кирпечкә куеп,
Тезен кочкан дәрвишләр.

Намазлыкка кырын яткан бу, тыңлана үзенчә. Дөньяның кай ягыннан килә өннәр? Рухлар дөньясыныкы түгелме? Әллә үз күңеленнен килгән өннәрдә әсеренгенме? Алай да була... Офыкныкы дип кабул иткәнең чынлыкта күңелеңнең күтәрелгән он булып чыга да, сине тирәнлеккә әйдәкли, үз-үзеңә – күңелеңә багындыра... күңел «алласына» юлыктыра, «күңелең алласын онытма – ул тудырган дөньяны» дип өйттәртә. Бер затлылык төсле тоела бу баштарак: «Үз алласын күңелендә тойган кеше бүтәннәргә дә, хәтта җан иясенең иң кече туганына да – бөҗәкләргә карата да инсафлы булган. Табигатькә табыну аның җанын матурлаган». Тәти тоелган мондый фәлсәфәгә, мәхлукатларга табыну кебек мондый бидгатькә чынлап торып күңел бирсәк, исерсәң-сихерләнсәк, бер-заманны «теге яктан» кан сораячаклар, вәхшилек китәчәк, адем чалу китәчәк! Акыл чөнки читкә киткән, бер Аллага бәгланмаган; андыйларның күңеленә төрле яктан, төрле катламнан һөҗүм бара; өннәргә уралып, вәсвәсәләнеп яшәгән күңел – Лаокоон ул.

Күңелеңә багыну, казыну, күңел «алласына» буй сону – рефлексия. Зурлык түгел. Ныклык түгел. Интеллектуальлек түгел.

Нарцисслык. Үз шәүләсенә гашыйк булып, судан күзен ала алмыйча һәлак булган Нерсис - рефлексиягә киная ул.

«Төшеп киттем, төшеп киттем, төшеп киттем түбән» дигән шигырь юллары – күңел дөньясында адаштырылганнарның бер аһыдыр. Даһи Бабич...

Иман нуры белән күңеле мөлдерәмә диндарда рефлексия юк! – Күңеленә багыну юк.

Интеллектуальлек - бер Аллага багланудa гына!

Бишвакыт намаз укучыда гына ул чын интеллектуаль тормыш. Пакьлек! – Азатлык! – Лаокоон түгел инде андый күңел.

Һәммәсе - мәхлукат: галәмнәр, күңелләр, «информацион-көч фазасы» («информационно-силовое пространство»), фәрештәсе-алиһәсе, ияләре-ниләре, кавем җаннары – «аллалары» (урыс вәхшие А.Дугин әнә үз кавемен «урыс алласы»на табындырмакчы!) һәммәсе - мәхлукат. Боларга тапшырылу, болардан көч сорау, ярдәм өмет итү – мәҗүсилек. Вәхшилек. «Солнцепоклонник»лар татарда үрчегән саен һәлакәт якыная!

Сәнгатькярләр арасында хөкем сөргән фикерчекләр: «дөньякүләм кимелдe» иҗат итәргә чакырып, «сюрреализм» ди-ди авыз суларын корытып лаф орулар, зәнки битлеклеренә биһуш булулар, символлар белан әвәрә килүләр (символның мәгънәсе Каббаладагы «өсте ничек – аста шулай» дигән фәлсәфәгә туры килә икән, ягьни «өс вә ас бердәй» дигән фикер чагылышы икән символ дигәнең. Шул ук мәҗүсилек бу. Тереләр свастикалар һ.б.).

Әйтелгәннәрне тулыландырып җибермәсме, дигән нияттән бер мисал да китерәм. Кер эзләү дип аңлашыла күрмәсең, зинһар. Моңарчы барыбыз да шушындый халәтне зурлык вә затлылык дип аңладык бит. «Көннәрдән беркөнне шулай далада сарык көтеп йөрим». – Сөргендәге тормышын танышына сөйләп торучы олуг шагыйребез сүзләре бу – Яңгыр ява башлады. Мин чыланудан куркып хафаланам. Чылангач киптерергә кирәк бит. Ә минем алмаш күлмәк-ыштан юк. Яңгыр коя башлаганда мин чишенеп өлгергeн идем инде. Киемемне кирза итек эченә тутырдым да, кунычы белән жиргә каплап, бастырып куйдым.

Күк күкри. Коеп яуган яңгыр астында такмаклап биергә тотынганмын. Мәҗүсилек килгән. Бию белен язмышка тәэсир итәм, янәсе. Карасам, мине төрле яктан сарыклар урап алганнар да, хәйран калып карап торалар...

Шул чакта минем шагыйрь көткән көтү эчендә сарыклар арасында буласым килеп китте. – Инде монысы – тыңлаучы авызыннан, аның хатирәсе. – Мәҗүсиләр биюен үз күзем белән күрәсем килә иде... Киң дала. Яңгырда бер дөм шәрә үз тәкъдирен өсти. Күк күкрәүдән, яшен яшьнәүдән туган светомузыка.

Биюченең күңеле башка дөньяда, ул үзе дә башка галәмдә... Юк, бию түгел бу. Бу – шаманнар башкара торган йола, ритуал. Шаман күкләрдән хакыйкать сорый».

Күңел башка дөньяда, башка галәмдә... Философтай «богауларны җимереп», үзебезчә азатлык дип уйланылган әрвахлар-рухлар дөньясына багыну, мәхлукларның тәэсиреннен вәсвәсәләнү, пычрану, пакьлекне җую – тәүхидтән мәхрүмлек! Һәлакәт дими ни дисең моны...

Адәм углы җиһаннар имамы итеп яратылган ләбаса!
Әмма бер Раббысын зурласа гына имамлык чынга ашар.
Күңелең бер Раббыга багласа гына чынга ашар.
Имамлык.
Билгеле сүзләр. Тотмыйбыз гына.
Шуңа да - күңелләр күңелсез.
Күңелләр – Лаокоон!

... «Әүлияләр мизгеле» менә шундый уйларга этерде. Тетрәнерлек рухи тәҗрибә – татарның яңа дәвергә әзерлеген, – халәте рухиясен күрдек без шушы ижатта...

*// Аргамак. – 1997. – № 9*